ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**10.07.2026** **Чистай ш.** **№ 292**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү буенча комиссия турында нигезләмәне һәм тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) заказчылар белән билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле органның үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау хакында» 2022 елның 30 мартындагы 224 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү максатларында (11.06.2022 № 160-ФЗ, 05.12.2022 № 498-ФЗ, 28.04.2023 № 154-ФЗ, 25.12.2023 № 624-ФЗ, 29.05.2024 № 124-ФЗ, 26.12.2024 № 484-ФЗ Федераль законнар редакциясендә), Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү буенча комиссия турында нигезләмәне һәм тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) заказчылар белән билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле органның үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау хакында» 2022 елның 30 мартындагы 224 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Карарның 1 нче кушымтасында (тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү буенча комиссия турында Нигезләмә):
1.1.1. 7.3 пунктында:
«ж» пунктчасының өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;
«о» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«о) Федераль законның 24 маддәсендәге 10 өлешенең 2 пунктындагы «г» пункт-часында, 33 маддәсендәге 1 өлешенең 1 пунктындагы «г» пунктчасында һәм 93 маддәсендәге 1 өлешенең 28 пунктында каралган, шәхси белешмәләрне шәхессезләндерү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында каралганны тәэмин итеп, табиблар комиссиясе карары».
1.1.2. 7.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7.4. Контрактлар реестрына, әгәр мондый контрактларда дәүләт сере булып тора торган белешмәләр булса, Федераль законның 93 маддәсендәге 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә төзелгән контрактлар турындагы мәгълүмат кертелми».
1.1.3. 5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5.5. Комиссия әгъзалары була алмыйлар:
1) сатып алуны гамәлгә ашыру турындагы хәбәрнамәне, сатып алу турындагы документларны (Федераль законда сатып алу турындагы документлар каралган очракта), конкурста катнашуга гаризаларны эксперт бәяләвен уздыруга экспертлар сыйфатында җәлеп ителгән физик затлар;
2) тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү нәтиҗәләрендә шәхси кызыксынуы булган физик затлар, шул исәптән тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашуга гаризалар биргән яисә гаризалар биргән оешмалар яки физик затлар белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы, яисә тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашуга гаризалар биргән оешмаларның идарәчеләре булган физик затлар). «Шәхси кызыксыну» төшенчәсе коррупциягә каршы көрәш турында 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән мәгънәдә кулланыла;
3) сатып алуда катнашуга заявкалар биргән оешмаларда катнашучылар (акционерлар), аларның идарә органнары әгъзалары, сатып алуда катнашучыларның кредиторлары булган физик затлар;
4) Федераль законның 99 маддәсендәге 1 өлешендә күрсәтелгән контроль органнарының сатып алулар өлкәсендә контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары.

Комиссия составында әлеге өлештә күрсәтелгән физик затлар ачыкланган очракта, комиссияне төзү турында карар кабул иткән заказчы аларны кичекмәстән әлеге өлештә каралган таләпләргә туры килә торган башка физик затлар белән алыштырырга тиеш».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э. Р. Хәсәнов